ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 13 статьяда түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

“3. Муниципаль берәмлекләр чикләрен билгеләү яисә үзгәртү турында Татарстан Республикасы законнары кабул ителгән очракта, “Дәүләт күчемсез милек кадастры турында” 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә җир төзелеше объектларының карталарын (планнарын) кадастр исәбенә алу органнарына җибәрү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.”;

3) 15 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

4) 18 статьяның 1 өлешендәге $4^1$ пунктында “коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларны (коммуналь комплекс оешмаларының – электр (яисә) җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә товар

җитештерүчеләрнең һәм хезмәт күрсәтүчеләрнең товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифлардан тыш),” сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 3 марты
№ 10-ТРЗ